**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең хезмәт таныклыгы формасы һәм аны бирү тәртибе турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затның таныклыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең хезмәт таныклыгы турында» 2006 елның 16 гыйнварындагы ПУ-8 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 августындагы ПУ-310 номерлы һәм 2014 елның 18 апрелендәге ПУ-377 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең хезмәт таныклыгы формасы һәм аны бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3.9 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Таныклык бланкларын әзерләү Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетында тиешле дәүләт органын тәэмин итүгә каралган акча хисабыннан мөстәкыйль башкарыла».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затның таныклыгы турында» 2007 елның 7 июнендәге ПУ-288 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-443 номерлы һәм 2014 елның 18 апрелендәге ПУ-377 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затның таныклыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 9 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

б) 14 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

в) 19 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 09 март
№ ПУ-218